**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**20.12.2019** **№ 2411**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне тормышка ашырганда, тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында”, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җир асты байлыклары турында”, 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы РФ Законының 5 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне тормышка ашырганда, тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын расларга (алга таба – Регламент).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф.Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта

Расланган
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
20.12.2019 № 2411

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне тормышка ашырганда, тикшерүләр үткәрүнең административ регламенты

## 1 бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Функциянең исеме – “Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга муниципаль контроль” (алга таба – муниципаль контроль).

Әлеге административ регламент белән (алга таба – Регламент, администратви регламент) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне тормышка ашыру җайга салына.

1.2. Муниципаль контрольне тормышка ашыручы җирле үзидарә органы исеме.

Муниципаль контрольне тормышка ашыручы җирле үзидарә органы – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль контрольне тормышка ашыру буенча функцияләрне “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесе тормышка ашыра (алга таба – муниципаль контроль органы).

1.3. Муниципаль контрольне тормышка ашырганда муниципаль контроль органы хезмәттәшлек итә:

- “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, юридик затларны тикшреүнең еллык планнарын әзерләү, бергә уздырылучы планлы тикшерүләрне уздыру буенча тәкъдимнәрне карау, урынга чыгып тикшерә торган планнан тыш тикшерүләрне килештерү мәсьәләләре буенча прокуратура органнары белән;

- төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән бергә уздырыла торган планлы һәм (яки) планнан тыш тикшерүләр уздыру юлы белән;

- гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм саклау өлкәсендә административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә беркетмәләр төзергә хокуклы органнарның вазыйфаи затлары белән административ хокук бозулар турында эшләр кузгату турында мәсьәләләрне чишү өчен.

1.4. Муниципаль контрольне тормышка ашыруны җайга салучы, реквизитларын һәм рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп, норматив хокукый актлар исемлеге.

- “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (түбәндәге басмаларда басылган: “РФ законнары җыелмасы”, 06.10.2003 № 40 3822 ст., “Парламентская газета”, 08.10.2003 № 186, “Российская газета”, 08.10.2003 № 202);

- “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (түбәндәге басмаларда басылган: “РФ законнары җыелмасы”, 29.12.2008 № 52 (1б.) 6249 ст., “Парламентская газета”, 31.12.2008 № 90, “Российская газета”, 30.12.2008 № 266);

- “Файдалы казылмалар турында”, 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Федераль закон (түбәндәге басмаларда басылган: “РФ законнары җыелмасы”, 06.03.1995 № 10, 823 ст., “Российская газета”, 15.03.1995 № 52);

- РФ Хөкүмәтенең “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарын әзерләү Кагыйдәләрен раслау турында”, 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (“РФ законнары җыелмасы”, 2010, № 28, ст. 3706 ст. басмасында басылган);

- Россия Икътисади үсеш министрлыгының “Дәүләт контролен (күзәтчелеге) һәм муниципаль контролне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”, 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (“Российская газета”, 14.05.2009, №85).

Муниципаль контрольне тормышка ашыруны җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге, аларның реквизитларын һәм финанслау чыганакларын күрсәтеп, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында мәҗбүри рәвештә басылып чыгарга тиеш.

1.5. Муниципаль контроль предметы

Муниципаль контроль предметы булып юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан федераль законнар, аның нигезендә кабул ителә торган башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары (алга таба – мәҗбүри таләпләр) таләпләрен тотуы, гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм саклау өлкәсендә билгеләнгән муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне тотуы тора.

1.6. Муниципаль контрольне тормышка ашырганда вазыйфаи затларның хокуклары һәм йөкләмәләре.

1.6.1. Вазыйфаи затлар хокуклы:

1) юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән тикшерү уздыру барышын карау өчен кирәкле, тикшерелергә тиешле мәсьәләләр буенча документларны һәм материалларны, шулай ук идарә органнарының, оешмалар, башка идарә органнары яки оешмаларның тикшерелергә тиешле мәсьәләләр буенча телдән һәм язмача аңлатмаларын алырга;

2) дәлилләнгән язмача соратулар нигезендә кирәкле мәгълүмат һәм документларны соратырга һәм алырга;

3) муниципаль контрольне тормышка ашыруга каршылык тудыручы гамәлләрне булдырмый калуга һәм (яки) туктатуга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм саклау өлкәсендә законнарны бозуда гаепле затларны билгеләү булышлык күрсәтүне сорап хокук саклау органнарына, контроль һәм күзәтчелек органнарына мөрәҗәгать итәргә;

4) вазыйфаи затларның хокукларын бозуга китергән, шулай ук алар тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрне үтәүгә каршылык тудыручы гамәлләргә (гамәл кылмауга), шикаять белдерергә;

5) 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 10 статьясы 2 бүлеге белән күздә тотылган мәгълүматны, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә алдан тикшерү уздырырга;

6) гражданиннан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, күрсәтелгән затлардан кергән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карауга, әлеге гаризаларда һәм мәгълүматларда алдан ук ялган мәгълүматлар күрсәтелгән булса, муниципаль контроль органы күтәргән чыгымнарны каплау турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә;

7) 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән күздә тотылган башка хокукларны тормышка ашырырга.

1.6.2. Вазыйфаи затлар тиешле:

1) билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне кисәтү, ачыклау һәм бетерү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә тәкъдим ителгән вәкаләтләрне вакытында һәм тулы күләмдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, тикшерү уздырыла торган юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тотарга;

3) муниципаль контроль органы җитәкчесе карар нигезендә тикшерүне аны уздыру турында аны билгеләү нигезендә уздырырга;

4) тикшерүне бары тик хезмәт йөкләмәләрен башкарган вакытта гына, урынга чыгып тикшерүне бары тик хезмәт таныклыгын, муниципаль контроль органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары карарлары күчермәләрен, 294-ФЗ номерлы Федераль закон 10 статьясы 5 бүлеге белән күздә тотылган очракларда, тикшерү уздыруны прокуратура органнары белән килештерү турында документ күчәрмәсен күрсәткәндә генә уздырырга;

5) җитәкчегә, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү уздырган вакытта анда булуга

һәм тикшерү предметына кагылган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә каршылык күрсәтмәскә;

6) тикшерү уздыру вакытында булган җитәкчегә, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына караган мәгълүматларны һәм документларны бирергә;

7) җитәкчене, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) җитәкчене, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән таныштырырга;

9) юридик затка, шәхси эшмәкәргә ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында, аны бетерү срокларын күрсәтеп, күрсәтмәләр бирергә;

10) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы 5-7 бүлекләре белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән таләпләрнең, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында алдан кисәтү булдерергә;

11) ачыкланган кагыйдә бозулар фактлары буенча кабул ителә торган аерым бер чараларны ачыклаганда, күрсәтелгән чараларның, кагыйдә бозуларның авырлыгына, аларның тормышка, кешеләр сәламәтлегенә, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), Россия Федерациясе музей фондалары составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча да кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аеруча да тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, милли китапханә фондына керүче документларга, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп тууга, шулай ук гражданнарның дәлилләнмәгән хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләүгә, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затларга потенциаль куркынычлылыгын истә тотарга;

12) үз гамәлләренең нигезлелеген расларга, Россия Федерациясе законнары тарафыннан юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан аларга шикаять белдерелгән вакытта;

13) законнар белән билгеләнгән тикшерү уздыру срокларын тотарга;

14) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән Россия Федерациясе законнары белән аларны тәкъдим итү күздә тотылмаган очракта, документлар һәм башка төр мәгълүматларны таләп итмәскә;

15) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратыла һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлегенә кертелгән, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, мунципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы карары белән расланган әлеге документлар һәм (яки) мәгълүматлар карамагында булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан (ведомствоара исемлек) яки дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарына

ведомство карамагында булган башка оешмалардан соратырга мөмкин булган документлар һәм (яки) мәгълүматларны, башка җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт органнарыннан яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарына ведомство карамагында күрсәтелгән документларны таләп итәргә.  Юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән башка җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары, яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарына ведомство карамагында булган  органнар карамагандагы, ведомствоара исемлеккә кертелгән рөхсәт бирү документларын да кертеп, документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела;

16) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән тикшерү башлану датасына кадәр документларны, мәгълүматларны, шулай ук алар алар тарафыннан документар тикшерү вакытында бирелгән документларны һәм (яки) мәгълүматларны бирүне таләп итмәскә;

17) урынга чыгып уздырыла торган тикшерү башланыр алдыннан, җитәкче, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча аларны әлеге административ регламентның нигезләмәләре белән таныштырырга;

18) уздырылган тикшерү турында юридик затларда, шәхси эшмәкәрләрдә тикшерүләр исәбен алып бару журналында (булган очракта) язманы тормышка ашырырга;

19) ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерүне контрольдә тоту, аларны кисәтү, тормышка, кешеләр сәламәтлегенә, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), Россия Федерациясе музей фондалары составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча да кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аеруча да тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, милли китапханә фондына керүче документларга зыян салуны булдырмый калу, дәүләт иминлеген тәэмин итүгә, табигый һәм техноген характердагы  гадәттән тыш хәлләр килеп тууны кисәтү  буенча чаралар күрергә, шулай ук әлеге ачыкланган кагыйдә бозуларны җибәргән затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә;

20) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы 2 бүлеге белән билгеләнгән зыян салуны булдырмый калу яки зыян салуны туктату буенча кичекмәстән чаралар күрү;

21) гражданнар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләргә мәгълүмат җиткерүнең теләсә нинди мөмкин булган юлы белән зыян салу куркынычы булу һәм аны булдырмый калу ысуллары турында мәгълүмат җиткерү;

22) муниципаль контроль органы компетенциясе чикләрендә, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән хезмәттәшлек итмичә, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.3 статьясы белән билгеләнгән тәртиптә, контроль буенча чаралар тормышка ашырырга;

23) планлы тикшерү уздыру алдыннан 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясы нигезләмәләрен җитәкчегә, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, аның  вәкаләтле вәкиленә аңлатырга;

23) мәҗбүри таләпләрне, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы белән күздә тотылган таләпләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм уздыру буенча чараларны тормышка ашырырга;

24) 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән башка таләпләрне тотарга.

1.7. Муниципаль контроль буенча чаралар тормышка ашырыла торган затларның хокуклары һәм йөкләмәләре.

1.7.1. Шәхси эшмәкәр һәм (яки) аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче, башка вазыйфаи зат һәм (яки) юридик затның вәкаләтле вәкиле хокуклы:

1) тикшерүне уздырганда турыдан-туры анда катнашырга;

2) тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

3) муниципаль контроль органыннан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметы һәм аларны тәкъдим итү 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законда күздә тотылган булса;

4) тикшерү нәтиҗәләре буенча танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышуны, алар белән, шулай ук муниципаль контроль органының вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән риза булу яки булмауны күрсәтергә;

5) тикшерү уздырылган юридик зат, шәхси эшмәкәр тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр, яисә ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү актын алган көннән унбиш көн дәвамында муниципаль контроль органына язма формада тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата тулаем яки аларның кайбер өлешеләренә каршы килүләр тәкъдим итәргә хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшмәкәр әлеге каршы килүләргә, әлеге каршы килешүләрнең нигезләрен, яки аларның расланган күчермәләрен беркетергә яисә килешенгән срокларда аларның муниципаль контроль органына бирергә хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификация мөһере куелып, электрон документ формасында (электрон документлар пакетлары) җибәрелергә мөмкин;

6) тикшерү уздырганда Юридик затларның хокукларын бозуга китергән муниципаль контроль органы вазыйфаи затының гамәлләренә (гамәл кылмауларына), Россия Федерациясе законнары нигезендә, административ яки суд тәртибендә шикаять белдерергә;

7) юридик зат, шәхси эшмәкәр муниципаль контроль органына, аларга карата планлы тикшерүләр уздыруның еллык планыннан төшерү турынңа гариза бирергә хокуклы, әгәр дә алар тикшерү уздыру планлы тикшерүләр уздыру еллык планына 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон статьялары нигезләмәләрен бозып куелган дип уйласалар;

8) муниципаль контроль органы тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, әлеге документлар һәм (яки) мәгълъматлар башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарына ведомство карамагында булган оешмалардан алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышырга;

9) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документлар һәм (яки) мәгълүматларны муниципаль контроль органына үз инициативасы белән тәкъдим итәргә;

10) соратуда булган документларны көчәйтелгән квалификацияле мөһер белән имзаланган электрон документ формасында тәкъдим итәргә;

11) 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән күздә тотылган башка хокукларны тормышка ашырырга.

1.7.2. Шәхси эшмәкәр һәм аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче һәм башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле тиешле:

1) тикшерү уздыручы вазыйфаи затның тикшерү уздыру урынына берниндиe тоткарлыксыз керә алуын;

2) муниципаль контроль органына дәлилләнгән соратудагы документларны сорату алынган көннән ун көн дәвамында җибәрергә;

3) муниципаль контроль органының ачыкланган мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозуларны билгеләнгән срокларда башкарырга;

4) урынга чыгып тикшерү уздыра торган муниципаль контроль органының вазыйфаи затларына, урынга чыгып тишерү максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле документлар белән танышырга мөмкинлек бирергә, урынга чыгып тикшерүгә кадәр документар тикшерү уздырылмаган булса;

5) 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән башка таләпләрне тотарга.

Тикшерү уздырган вакытта юридик зат һәм шәхси эшмәкәр мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне башкару буенча чараларны оештыру һәм уздыру өчен җаваплы җитәкчеләрнең, башка вазыйфаи затларның яки вәкаләтле вәкилләрнең анда булуын тәэмин итәргә тиеш;

1.8. Муниципаль контрольне тормышка ашыру нәтиҗәсе тасвирламасы.

Муниципаль контрольне тормышка ашыру нәтиҗәсе булып тора:

- әлеге админстратив регламентның 3.6.8 пунктчасы нигезендәге форма буенча муниципаль контроль органының тикшерү актын төзү;

- мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, күрсәтмә бирелә, ачыкланган кагыйдә бозулар турында материаллар вазыйфаи затлары административ кагыйдә бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы, “Административ кагыйдә бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы” 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклау өлкәсендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы органга җибәрелә (административ хокук бозулар сыйфатлары булган мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта).

1.9. Муниципаль контрольне тормышка ашыру өчен кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүматларның тулы исемлеге һәм тикшерү уздыруның максатларына һәм бурычларына ирешү.

1.9.1. Тикшерү барышында шәхсән юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән таләп ителә торган документлар һәм (яки) мәгълүматларның тулы исемлеге:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокук билгеләүче документлары;

2) юридик зат исеменнән ышанычнамәсез гамәл кылырга хокукы булган физик затны вазыйфага билгеләү яки сайлап кую турында карар яисә боерык;

3) тикшерелә торган юридик затның, шәхси эшмәкәрнең вәкиленең муниципаль контроль буенча чараларны тормышка ашырганда (тикшерелә торган юридик затның мөһере белән расланган (мөһер булган очракта) һәм аның җитәкчесе яки әлеге җитәкче тарафыннан вәкаләтле зат тарафыннан кул куелган Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә (юридик затлар өчен) яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә (шәхси эшмәкәрләр өчен)) вәкаләтләрен раслаучы һәм аның җитәкчесе яки әлеге җитәкче тарафыннан вәкаләтле зат кул куйган (юридик затлар өчен) документ.

4) тикшерүләрнең исәбен алу журналы (булган очракта);

5) җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документлар;

6) күчемсез милек объектына хокук билгеләүче документлар;

7) җир кишәрлеген фактта кулланучы белән төзегән аренда шартнамәсе (булган очракта);

8) гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда әйләнә-тирә мохиткә начар тәэсирне киметүче чаралар турында мәгълүмат.

1.9.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында башка җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт органнарыннан, дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына ведомство карамаганыда булган оешмалардан соратыла һәм алына торган документларның һәм (яки) мәгълүматларның тулы исемлеге, ведомствоара исемлек нигезендә:

1) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар;

2) Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар;

3) Күчемсез милек объекты турында бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

4) күчемсез милек объектына хокуклар күчүе турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

5) файдалы казылмалар белән куллануга бердәм дәүләт лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар.

## 2 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬНЕ ТОРМЫШКА АШЫРУГА ТАЛӘПЛӘР

2.1. Функцияне башкару турында мәгълүмат бирү тәртибе.

2.1.1. Функцияне башкару турында мәгълүмат юридик затларга һәм физик затларга, шәхси эшмәкәрләргә бирелә (алга таба – гариза бирүчеләр):

- муниципаль контроль органнарына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә;
- муниципаль контроль органнары биналарындагы мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән;
- телефон элемтәсе чараларын куллынып;
- язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ формасында) – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша..

Муниципаль контроль органнарының урнашкан урыны, эш графигы, телефон номерлары:

Биектау авылы, Полковая урамы, 9 нчы йорт.

Эш графигы:
Дүшәмбе, сишәмбе: 8.00 дән 17.00гә кадәр;
пәнҗешәмбе — 8.00 дән 12.00гә кадәр
чәршәмбе, җомга – кабул итү көннәре түгел;
шимбә, якшәмбе – ял көннәре.
Төшке аш: 12.00 дән 13.00 гә кадәр.
Белешмә өчен телефон
Палата: 8(84365) 3-28-54.

Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

Белешмә өчен мәгълүмат мәҗбүри рәвештә Биектау муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә (http://vysokaya-gora.tatar.ru), “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры” дәүләт мәгълүмат системасында һәм Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында урнаштырылырга тиеш.

2.1.2. Муниципаль контрольне тормышка ашыру тәртибе турында мәгълүмат бирүне тәэмин итү өчен түбәндәге мәгълүмат тәкъдим ителә:

- муниципаль контроль органы исеме;
- муниципаль контроль органының почта адресы;
- муниципаль контроль органының, вазыйфаи затларның телефон номерлары, электрон почталары адреслары;
- муниципаль контроль органының, вазыйфаи затларның эш графигы (режимы);
- муниципаль контроль органы актларына (карарларына), аларның вазыйфаи затларының гамәлләрен яки гамәл кылмауларына шикаять белдерү тәртибе;
- муниципаль контрольне тормышка ашыруны җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге һәм чыгарылмалар.

2.1.3. Гариза бирүчеләргә мәгълүмат бирү телдән яки язмача формада, электрон рәвештә тормышка ашырыла.

Гариза бирүчеләргә мәгълүмат җиткерүнең төп таләпләре булып тора:

- бирелә торган мәгълүматларның дөреслеге;
- мәгълүматны бәян итүдә төгәллек;
- мәгълүмат җиткерүнең тулылыгы;
- мәгълүмат алуның җайлылыгы һәм ала алу мөмкинлеге.

2.1.3.1. Телдән мәгълүмат җиткерү гариза бирүче мәгълүмат артыннан шәхсән үзе яки телефон буенча мөрәҗәгать иткәндә тормышка ашырыла.

Телдән җаваплар төгәл, аңлау өчен гади, ике төрле итеп шәрехләүне киткреп чыгармый торган булырга тиеш. Консультацияне тормышка ашыручы вазыйфаи затлар җавапны мөстәкыйль рәвештә бирәләр, кызыксынган затларга карата, аларның намус һәм абруйларына хөрмәт белән, игътибарлы һәм яхшы мөнәсәбәт күрсәтәләр.

Әгәр дә телдән җавап бирү өчен озак вакыт таләп ителсә яки кызыксынган зат алынган мәгълүматтан канәгать булмаса, кызыксынган затларга язмача формада мәгълүмат алу яисә кызыксынган затларга уңайлы теләсә кайсы вакытта төгәлрәк телдән консультация алу өчен уңайлырак вакыт билгеләнелә.

Консультацияне тормышка ашыручы вазыйфаи затта кирәкле мәгълүмат булмаган очракта, сорау башка вазыйфаи затка адресланырга мөмкин яки

кызыксынган затка кирәкле мәгълүматлары булган оешмалар, структур бүлекчәләр, вазыйфаи затлар турында мәгълүмат җиткерелә.

Шәхсән үзе телдән мәгълүмат җиткерүне тормышка ашыручы муниципаль контроль органы хезмәткәре, куелган сорауга тулы һәм оператив җавап бирү өчен барлык кирәкле чараларны күрергә тиеш, шул исәптән, муниципаль контроль органының башка хезмәткәрләрен җәлеп итеп.

Гариза бирүче шәхси телдән мәгълүмат алганда чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Әгәр дә җавапны әзерләү өчен озаграк вакыт таләп ителсә, шәхсән телдән мәгълүмат бирүне тормышка ашыручы муниципаль контроль органы хезмәткәре гариза бирүчегә кирәкле мәгълүматны язмача рәвештә алу турында мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итә.

2.1.3.2. Муниципаль контроль органына гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхси телдән мәгълүмат бирү җавапны почта аша җибәрү юлы белән тоомышка ашырыла.

Язмача сорату кергәндә муниципаль контроль органы җитәкчесе, аның урынбасары җавапны әзерләү өчен турыдан туры башкаручыны билгелиләр.

Гариза бирүче мөрәҗәгатенә җавап  гади, ачык һәм аңлаешлы формада башкаручының фамилиясе һәм телефон номерын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты Җитәкчесенең (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе) имзасы белән бирелә.

Җавап язмача формада, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә.

Физик затларның язмача мөрәҗәгатьләре “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”, 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карала.

2.1.3.2. Электрон почта аша мәгълүмат җибәрелгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап гариза бирүченең электрон адресына яисә мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән башка адреска, муниципаль контроль органында  мөрәҗәгатьне теркәү көненнән 30 көннән артмаган срокта җибәрелә.

2.1.4. Муниципаль контроль органының мәгълүмати стендларында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

- муниципаль контроль органының эш режимы;

- гариза бирүчеләрне кабул итү һәм мәгълүмат җиткерү тормышка ашырыла торган кабинетларның номерлары, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм мәгълүмат җиткерүне тормышка ашыручы белгечләрнең фамилияләре, исемнәре, әтисенең исемнәре һәм вазыйфалары;

- муниципаль контроль органының телефон номерлары, факсы, электрон почта адресы, Биектау муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә адресы;

- гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм саклау өлкәсендә законнар турында мәгълүмат;

- әлеге административ регламент.

2.1.5. Муниципаль контрольне тормышка ашыру тәртибе турында мәгълүмат Биектау муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырыла.

2.2. 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьялары белән күздә тотылган һәрбер тикшерү уздыруның срогы егерме көннән дә артырга тиеш түгел.

Кече эшмәкәрлекне бер субъектына карата планлы тикшерүләр уздыруның гомуми срогы елга кече предприятие өчен илле сәгатьтән дә артмаска, ә микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтә артмаска тиеш.

Искәрмә очракларында, урынга чыгып планлы тикшерү уздыручы муниципаль контроль органы вазыйфаи затының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) дәвамлы тикшерүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр уздыру кирәк булганда, урынга чыгып планлы тикшерү уздыру срогы Башкарма комитет Җитәкчесе яки ул булмаган чорда аның вәкаләтләрен башкаручы, ләкин егерме эш көненнән дә артмаган чорда, вазыйфаи зат карары белән, кече предприятиеләр өчен илле сәгатьтән дә артмаска, ә микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтә артмаска тиеш.

Кече эшмәкәрлек субъектына планлы урынга чыгып тикшерү уздыру кирәк булган очракта, әлеге тикшерүнең ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар алу Башкарма комитет Җитәкчесе, яки ул булмаган чорда аның вәкаләтләрен тормышка ашыручы зат карары буенча, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне тормышка ашыру өчен кирәкле вакытка туктатып торылырга мөмкин, ләкин ун эш көненнән дә артык булмаган срокка. Тикшерү уздыруны кабаттан туктытып тору рөхсәт ителми.

Тикшерелә торган затка тикшерү срогы арттырылу, тикшерүне туктатып тору турында мәгълүмат язмача формада, шулай ук телефон һәм факсимиль элемтә, электрон почта аркылы, билгеле карарга кул куйган көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча җиткерелә.

2.3. Муниципаль функцияне башкаруда катнашучы экспертлар, контроль буенча чараларны тормышка ашыручы эксперт һәм башка оешмаларның хезмәтләре өчен түләү контроль буенча чаралар тормышка ашырыла торган затлардан алынмый.

### 3 бүлек. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ СРОКЛАРЫ, АЛАРНЫ БАШКАРУ ТӘРТИБЕНӘ ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ БАШКАРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

3.1. Муниципаль контрольне тормышка ашыру үз эченә түбәндәге административ процедураларны ала:

- юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тикшерүләрне планлаштырганда гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм саклау өлкәсендә законнарны тоту;
- тикшерү уздыру турында карар чыгару;
- урынга чыгып планнан тыш тикшерүне Биектау районы прокуратурасы белән килештерү, әгәр дә тикшерү прокуратура органнары белән килештерелергә тиеш булса;

- тикшерү уздыру һәм нәтиҗәләрне рәсмиләштерү.

Муниципаль контрольне тормышка ашыру блок схемасы щлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

3.2. Муниципаль контрольне тормышка ашыруның югары чик срогы әлеге Регламентның 2.2 бүлегендә билгеләнелгән.

3.3. Тикшерүләрне планлаштыру административ процедурасы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм саклау өлкәсендә законнарны тоту үз эченә түбәндәге чараларны ала:

3.3.1. Планлы тикшерүләр елына кадәр килүче елның 1 сентябренә кадәр муниципаль контроль органнары билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнарына планлы тикшерүләр уздыруның еллык план проектларын җибәрәләр.

3.3.2. Муниципаль контроль органы прокуратура органнары тәкъдимнәрен карый һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча прокуратура органнарына планлы тикшерүләр уздыру елына кадәр килүче елның 1 ноябренә кадәр прокуратура органнарына расланган планлы тикшерүләр уздыруның еллык план проектларын җибәрәләр.

Планлы тикшерүләр уздыруның еллык план проектларын әзерләү тәртибе, аны прокуратура органнарына тәкъдим итү һәм килештерү, шулай ук планлы тикшерүләр уздыруның еллык план проектларының типик формалары РФ Хөкүмәтенең "Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарын әзерләү Кагыйдәләрен раслау турында", 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары белән расланган.

3.3.3. Планлы тикшерүне планлы тикшерү планнарына кертү өчен нигез булып, юридик затка, шәхси эшмәкәргә дәүләт теркәве узган көннән, яисә юридик затка, шәхси эшмәкәргә ахыргы планлы тикшерү уздыру көненнән өч ел узу тора.

3.3.4. Административ процедураны башкаруны туктатып тору 292-Фз номерлы Федераль законның 13 статьясы таләпләре белән күздә тотылган очракларда һәм тәртиптә мөмкин.

3.3.5. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм саклау өлкәсендә законнарны тотуны тикшерү планлаштыру административ процедурасын башкару нәтиҗәсе булып, муниципаль контроль органы җиткәчесе тарафыннан расланган юридик һәм физик затларга тикшерүләр уздыруның еллык планы тора.

3.4. Административ процедураны башлау өчен нигез булып Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан тикшерү уздыру карарын чыгару тора:

- юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тикшерүнең еллык планында күрсәтелгән тикшерү уздыруны башлау датасына кадәр өч атна срокның башлануы;

- әлеге административ регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән планнан тыш тикшерү уздыруга нигезләр булуы.

3.4.1. Башкарма комитет җитәкчесенең яки аның вәкаләтләрен ул вакытлыча булмаган вакытта тормышка ашыручы затны планнан тыш тикшерү уздыру турында карарын чыгаруга нигез булып тора (алга таба – тикшерү уздыру турында карар):

3.4.1.1. Моңа кадәр бирелгән мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозу турында ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында карарның башкару срогы тулу.

3.4.1.2. Муниципаль контроль органының вазыйфаи затының, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән хезмәттәшлек итмичә контроль буенча чараларның нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәсендә, муниципаль контроль органына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын карау, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләи мәгълхмат чараларыннан түбәндәге фактлар буенча:

а) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), Россия Федерациясе музей фондалары составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча да кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аеруча да тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, милли китапханә фондына керүче документларга зыян салу куркынычы, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туу куркынычы;

б) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), Россия Федерациясе музей фондалары составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча да кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аеруча да тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, милли китапханә фондына керүче документларга зыян салу, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туу;

3.4.2. Муниципаль контроль органына мөрәҗәгать иткән затны билгеләп булмый торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге Регламентның 4.4.1.2. пунктчаларында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматлар булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып тора алмый.

Әгәр дә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат әлеге Регламентның 3.4.1.2. пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып торса, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты, мөрәҗәгатьнең һәм гаризаның авторлыгында нигезле шикләнүләр булган очракта, мөрәҗәгать иткән затны билгеләү буенча акылга сыя торган чаралар күрергә тиешле.

Гариза бирүче тарафыннан электрон документлар формасында җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып торырга мөмкин, ләкин бары тик алар гариза бирүче тарафыннан, идентификация һәм аутентификация бердәм системасында гариза бирүчеләргә мәҗбүри авторизация уздыруны күздә тотучы мәгълүмат-коммуникацион технологияләр чараларын кулланып җибәрелгән булу шарты белән.

Мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны караганда, Регламентның 3.4.1.2. пунктында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүмат, моңа кадәр кертелгән охшашалы мөрәҗәгатьләр һәм гаризаларның, мәгълүматларның, шулай ук билгеле юридик затлар, шәхси эшмәкәрләргә карата моңа кадәр контроль буенча уздырылган чараларның нәтиҗәләрен истә тотарга тиешләр.

3.4.3. Мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозган зат, Регламентның 3.4.1.2 пунктында күрсәтелгән фактлар турында ышанычлы мәгълүмат булмаган очракта, муниципаль контроль органының вәкаләтле заты тарафыннан кергән мәгълүматны алдан тикшерү уздырылырга мөмкин, аның барышында гариза һәм мөрәҗәгатьләрне җибәргән, мәгълүматларны тәкъдим иткән затлардан өстәмә мәгълүматлар һәм материаллар сорату турында чаралар кабул ителә (шул исәптән телдән дә), муниципаль контроль органы карамагында булган юридик затның, шәхси эшмәкәрнең документларын карау уздырыла, кирәк булган очрактаюридик зат, шәхси эшмәкәр белән мөнәсәбәтләргә кермичә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат бирү һәм муниципаль контроль органнары таләпләрен башкару буенча йөкләмәләрне йөкләмичә контроль буенча чаралар уздырыла. Алдан тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән алынган мәгълүматка карата аңлатмалар алыну соратылырга мөмкин, ләкин әлеге аңлатмаларны һәм башка документларны тәкъдим итү мәҗбүри булып тормый.

Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозуны җибәргән затлар, Регламентның 3.4.1.2 пунктында күрсәтелгән фактлар турында кирәк кадәр мәгълүмат ачыкланган вакытта, муниципаль контроль органының вәкаләтле вазыйфаи заты планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилләнгән күрсәтмә әзерли. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшмәкәрне җаваплылыкка тарту буенча чаралар кулланылмый.

Муниципаль контроль органы җитәкчесе, җитәкчес урынбсары карары буенча планнан тыш тикшерү әгәр дә билгеле тикәерү башланганнан соң,аны уздыру өчен сәбәп булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның анонимлыгы ачыклангач яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризадагы алдан ук ялган мәгълүматлар булган очракта туктатыла.

3.4.4. Тикшерү тикшерү уздыру турында карар нигезендә уздырыла.

Еллык тикшерүләр планы белән билгеләнгән планлы тикшерү уздыру датасына кадәр 10 эш көне алдан яки планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып торган документлар алу вакытыннан ике эш көненнән дә соңга калмыйча, тикшерү уздыру өчен муниципаль контроль органының вазыйфаи заты тикшерү уздыру турында карар проектын ике нөсхәдә, Россия Икътисади үсеш министрлыгының “Дәүләт контролен (күзәтчелеге) һәм муниципаль контролне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”, 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – РФ ИҮМ 141 номерлы боерыгы) белән расланган типик формада әзерли һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә яки ул вакытлыча булмаган вакытта аның вазыйфаларын башкаручыга затка имза куюга җибәрә.

3.4.5. Административ процедураны башкаруның нәтиҗәсе булып тикшерү уздыру турында Башкарма комитет Җитәкчесе яки ул вакытлыча булмаганда аның

йөкләмәләрен башкаручы зат тарафыннан имза куелган конкрет юридик зат яки шәхси эшмәкәргә карата тикшерү уздыру турында карар чыгару тора.

3.4.6. Юридик зат яки шәхси эшмәкәргә карата тикшерү уздыру турында карар чыгару административ процедурасын башкару сроклары.

3.4.6.1. Планлы тикшерү уздыру турында карар тикшерү уздыру башланганчыга кадәр 10 көннән дә артмаган вакытта басыла.

3.4.6.2. Планнан тыш урынга чыгып тикшреү уздыру турында карар, планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру өчен нигез булып торган мәгълүматларны үз эченә алган документларны алган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча басыла.

3.5. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруның прокуратура органнары белән килештерү адмиристратив процедурасын башлау өчен нигез булып муниципаль контроль органына 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 б. "а", "б" пунктчалары белән күздә тотылган фактлар турында мәгълүмат керү, шулай ук юридик зат яки шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш тикшерү уздыру турында карар тора.

3.5.1. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында карарны имзалаган көндә аны уздыруны килештерү максатларында муниципаль контроль органы, РФ ИҮМ 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеген тормышка ашыру урыны буенча Биектау районы прокуратурасына, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ формасында яки тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы хат рәвешендә почта аша планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында гаризаны җибәрә. Әлеге гаризага планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында карар күчермәсе һәм аны уздыру өчен нигез булып торган мәгълүматларны үз эченә алган документлар беркетелә.

3.5.2. Әгәр дә планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру өчен нигез булып гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), Россия Федерациясе музей фондалары составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча да кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аеруча да тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, милли китапханә фондына керүче документларга зыян салу, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туу, мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлардагы мәҗбүри таләпләрне бозулар булу ачыкланса, әлеге кагыйдә бозуларны ачыклаган вакытта, ашыгыч чаралар кабул итү кирәклеге белән бәйле рәвештә муниципаль контроль органы планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруга Биектау районы прокуратурасын контроль буенча чаралар уздыру турында 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 ст. 6 һәм 7 бүлекләре белән күздә тотылган документларны җибәрү аркылы хәбәр биреп, кичекмәстән керешергә хокуклы.

3.5.3. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны Биектау районы прокуратурасы белән килештерү административ процедурасы (юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне тикшергәндә) нәтиҗәсе булып планнан тыш урынга чыгып

тикшерү уздыруны килештерү турында карар яисә аны уздыруны килештерүдән баш тарту тора.

3.6. Тикшерү уздыру административ процедурасын башлау һәм аның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү өчен нигез булып тора:

- юридик зат, шәхси эшмәкәргә планлы тикшерү узлырган вакытта – планлы тикшерү уздыру турында карар;

- юридик затка, шәхс эшмәкәргә планнан тыш урынга чыгып тикшерү узлырган вакытта – планнан тыш тикшерү уздыру турында карар, шулай ук Биектау районы прокуратурасыннан алынган тикшерү уздыруны килештерү (әгәр дә тикшерү прокуратура органнары белән килешетерелергә тиеш булса).

3.6.1. Тикшерү уздыру, тикшерү уздыру турында карарда күрсәтелгән муниципаль контроль органы вазыйфаи заты (вазыйфаи затлары) тарафыннан тормышка ашырыла.

Муниципаль контроль органының документар тишерү уздыру өчен җаваплы вазыйфаи заты булып, Башкарма комитет яки ул вакытлыча булмаганда аның вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан тикшерү уздыруга вәкаләтле муниципаль контроль органы вазыйфаи заты тора (алга таба – тикшерүче).

3.6.2. Тикшерү тикшерү уздыру турында боерыкта күрсәтелгән срокларда уздырыла.

3.6.3. Юридик зат, шәхси эшмәкәр планлы тикшерү уздыру турында муниципаль контроль органы тарафыннан, ул башланганчыга кадәр өч көннән дә соңга калмыйча планлы тикшерү уздыру башлануы турында карар күчермәсен тапшыру турында хәбәр биреп заказлы почта аша җибәрү аркылы һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган һәм юридик зат, шәхси эшмәкәрнең электрон почтасы адресы буенча электрон документ җибәрү аркылы, әгәр дә әлеге адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләр бердәм дәүләт реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан муниципаль контроль органына җибәрелгән булса, яки башка мөмкин булган ысул белән хәбәр бирелә.

Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 ст. 2 бүлеге, 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш урынга чыгып тикшерүгә нигезләрдән кала, юридик зат, шәхси эшмәкәр муниципаль контроль органы тарафыннан, аны уздырганчыга кадәр егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча теләсә нинди мөмкин булган ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган һәм юридик зат, шәхси эшмәкәрнең электрон почтасы адресы буенча электрон документ җибәрү аркылы, әгәр дә әлеге адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләр бердәм дәүләт реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан муниципаль контроль органына җибәрелгән булса, хәбәр бирелә.

3.6.4. Әгәр дә юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), Россия Федерациясе музей фондалары составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча да кыйммәтле, шул исәптән

уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аеруча да тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, милли китапханә фондына керүче документларга зыян китерелгән булса яки китерелсә, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы  гадәттән тыш хәлләр килеп туган яки туарга мөмкин булса, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш урынга чыгып тикшерү башлану турында алдан хәбәр җибәрү таләп ителми.

3.6.5. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр документар тикшерү һәм (яки) урынга чыгып тикшерү документар тикшерү һәм (яки) урынга чыгып тикшерү формасында 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьяларында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

3.6.6. Документар тикшерүнең предметы булып тора:

- юридик зат, шәхси эшмәкәрнең оештыру-хокукый формаларын билгеләүче документлардагы мәгълүматлар, хокуклар, йөкләмәләр аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда кулланыла торган һәм алар тарафыннан мәҗбүри таләрләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне башкару белән бәйле документлар, муниципаль контроль органы күрсәтмәләрен башкару.

3.6.6.1. Документар тикшерү (планлы да, планнан тыш та) муниципаль контроль органының урнашкан урыны буенча уздырыла.

3.6.6.2. Тикшерүче  муниципаль контроль органы карамагында булган юридик зат, шәхси эшмәкәрнең документларын, алдагы тикшерү актларын, административ хокук бозулар турында эшләрне карау материалларын һәм юридик һәм шәхси эшмәкәргә карата тормышка ашарылган дәүләт һәм муниципаль контроль нәтиҗәләре турында башка документларны карый.

3.6.6.3. Муниципаль контроль органнары карамагында булган документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шикләр уяту, яисә әлеге мәгълүматлар тикшерү уздырыла торган затка карата мәҗбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне  башкаруына бәя бирергә мөмкинлек бирмәү очрагында, тикшерүче шәхси эшмәкәр, юридик зат адресына муниципаль контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) имзасы белән  документар тикшерү барышында  карау өчен кирәкле башка документларны тәкъдим итүне таләп итеп дәлилләнгән сорату җибәрә һәм тикшерә торган затны, аның вәкаләтле вәкилен телефон яки электрон элемтә аркылы дәлилләнгән сорату җибәрелә турында хәбәр итә.

Сорату тапшыру турында хәбәр бирү белән заказлы почта аша җибәрелә, соратуга  документар тикшерү уздыру турында боерык күчермәсе мөһер белән расланып беркетелә.

Шәхси эшмәкәрдән, юридик заттан яки аларның вәкаләтле вәкилләреннән соратуга җавап килгәндә тикшерүче тәкъдим ителгән документларның соратуга туры килү һәм тулылыгы фактын билгели.

3.6.6.4. Әгәр дә документар тикшерү барышында тикшерелә торган зат, аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан тәкъдим ителгән документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар булган очракта, яки әлеге документларда булган мәгълүматларның муниципаль контроль органнары карармагында булган һәм (яки) муниципаль контрольне тормышка ашыру барышында алынган документлардагы мәгълүматларга туры килмәсә,  тикшерүче бу хакта, кирәкле аңлатмаларны ун эш көне дәвамында

язмача тәкъдим итү таләбе белән мәгълүмат әзерли, шәхси эшмәкәр, юридик зат адресына тапшыру турында хәбәр белән заказлы почта ашаш җибәрә һәм аларны телефон яки электрон элемтә аркылы мәгълүмат җибәрү турында хәбәр бирә.

3.6.6.5. Тикшерүче шәхси эшмәкәр, юридик зат яки аларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан тәкъдим ителгән, алдагы тәкъдим ителгән документларның дөреслеген раслаучы аңлатмаларны һәм документларны карарга тиешле.

Тикшерүче тарафыннан шәхси эшмәкәр, юридик зат яки аларның вәкаләтле вәкилләре тәкъдим иткән аңлатмаларда һәм документларда мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозу билгеләре билгеләнгән очракта, яисә аңлатмалар булмаган очракта, муниципаль контроль органы урынга чыгып тикшерү уздырырга хокуклы.

Әгәр дә каралган мәгълүматлар шәхси эшмәкәр, юридик зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар таләпләрен башкаруга бәя биререгә мөмкинлек бирсә, тикшерүче аларга бәя бирә һәм тикшерү актын ике нөсхәдә РФ ИҮМ 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча тикшерү актын әзерли.

3.6.7. Урынга чыгып тикшерү (планлы да, планнан тыш та) юридик затның урнашкан урыны буенча, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеген тормышка ашыру урыны буенча һәм (яки) аларның үз эшчәнлекләрен фактта тормышка ашыру урыннары буенча уздырыла.

3.6.7.1. Әгәр дә документар тикшерү барышында түбәндәгеләрне ачыкларга мөмкин булмаса, урынга чыгып тикшерү уздырыла:

- тикшерелә торган шәхси эшмәкәр, юридик затка карата муниципаль контроль органы карамагында булган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшереп белергә;

- шәхси эшмәкәрнең, юридик затның эшчәнлеге мәҗбүри таләпләргә һәм муниципаль хокукый актлар таләпләренә туры килүен муниципаль контроль буенча билгеле чаралар уздырмыйча гына туры килүенә бәя бирергә.

3.6.7.2. Урынга чыгып тикшерү предметы булып юридик зат, шәхси эшмәкәр документларында булган мәгълүматлар, шулай ук аларның хезмәткәрләренең туры килүе, территорияләр, биналар, корылмалар, җиһазлар, охшаш объектларны, транспорт чаралары эшчәнлеген тормышка ашырганда күрсәтелгән затлар тарафыннан куллану халәте, юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан башкарыла торган эшләр һәм (яки) тәкъдим ителә торган хезмәтләр, шулай ук алар тарафыннан кабул ителә торган мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне башкару буенча чаралар.

3.6.7.3. Тикшерүче тикшерү уздыру урынына килгәннән соң, хезмәт таныклыгын күрсәтә һәм имза куйдырып җитәкчене яки юридик затның башка вазыйфаи затын, аның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне яки аның вәкаләтле вәкилен урынга чыгып тикшерү уздыруны билгеләү турында карар һәм урынга чыгып тикшерү уздыручы затның вәкаләтләре, шулай ук контроль буенча тикшерү уздыруның максатлары, бурычлары, нигезләре, чаралар төрләре һәм күләмнәре, тикшерү уздыру сроклары һәм шартлары белән таныштыра.

3.6.7.4. Әгәр дә урынга чыгып тикшерү алдыннан документар тикшерү уздырылмаган булса, тикшерүче урынга чыгып тикшерү максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле документлар белән таныша.

3.6.8. Урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерүче ике нөсхәдә РФ ИҮМ 141 номерлы боерыгы белән расланган формада тикшерү акты әзерли.

3.6.9. Тикшерү актында күрсәтеләләр:

- тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;

- тикшерү уздыручы муниципаль контроль органы исеме;

- тикшерү уздырылган Башкарма комитет Җитәкчесе яки ул вакытлыча булмаганда аның йөкләмәләрен башкаручы затның карары датасы һәм номеры;

- тикшерү уздырган вазыйфаи затның  (вазыөфаи затларның) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) һәм вазыйфасы;

- тикшерелә торган юридик затның исеме яки шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), шулай ук җитәкченең, юриди кзатның башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, тикшерү уздырганда булган башка физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) һәм вазыйфасы;

- тикшерү уздыруның датасы, вакыты, дәвамлылыгы һәм уздыру урыны;

- тикшерү уздыру нәтиҗәләре турында мәгълүматлар, шул исәптән ачыкланган мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне бозулар, аларның характеры, күрсәтелгән кагыйдәләрне бозган затлар турында мәгълүматлар;

- җитәкченең, юридик затның вазыйфаи затының як вәкаләтле вәкилнең, шәхси эшмәкәрнең, тикшерү уздыру вакытында булган аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында, аларның имзалары булу турында яки имза куюдан баш тарту турында мәгълүматлар;

- уздырылган тикшерү турында тикшерүләр исәбен алып бару журналына мәгълүматлар кертү турында, яки андый язманы юридик затта, шәхси эшмәкәрдә күрсәтелгән журналның булавы нәтиҗәсендә кертеп булмавы турында мәгълүматлар;

- тикшерү уздырган вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) имзасы.

3.6.9.1. Әгәр дә тикшерү актын төзү өчен уздырылган тикшерүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертиза нәтиҗәләре буенча йомгаклау алу кирәк булса, тикшерү акты контроль буенча чараларны тәмамлаганнан соң өч көннән артмаган срокта төзелә, һәм җитәкчегә, юридик затның башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә расписка белән бирелә яисә тапшыру турында хәбәр белән заказлы хат белән почта аша һәм (яки) әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган электрон документ формасында (тикшерә торган затның муниципаль контроль кысаларында электрон формада хезмәттәшлекне тормышка ашырырга ризалык булган очракта), әлеге документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрелә. Шул ук вакытта тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яки) күрсәтлегән документны алуны раслау муниципаль контроль органыныда саклanучы тикшерү акты нөсхәсенә беркетелә.

3.6.9.2. Тикшерү актына  уздырылган тикшерүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның  беркетмәләре яки бәяләмәләре, мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозу өчен җаваплы юридик затның, шәхси

эшмәкәрнең хезмәткәрләре аңлатмалары, ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерүнең нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар һәм аларның күчермәләре беркетелә.

3.6.9.3. Тикшерү акты турыдан-туры тәмамланганнан соң, ике нөсхәдә тутырыла.

Тикшерү актының бер нөсхәсе кушымталарның күчермәләре белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышу турында яисә танышудан баш тарту турында расписка белән тапшырыла.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тишерү уздырылган затның баш тартуы очрагында тикшерү акты белән танышу турында яисә танышудан баш тарту турында расписка бирергә, ул тапшыру турында хәбәр биреп заказлы почта аша җибәрелә, акт нөсхәсе белән тикшерү материалларына беркетелә.

Муниципаль контроль кысаларында электрон формада мөнәсәбәтләрне тормышка ашыруга тикшерелә торган затның ризалыгы булган очракта, әлеге тикшерү актын төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тикшерү акты электрон документ формасында җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта әлеге тикшерү актын төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тикшерү акты электрон документ формасында тикшерелә торган затка күүрсәтелгән документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрү, тикшерелә торган зат тарафыннан алынган булып санала.

Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру өчен аны уздыруны прокуратура органнары белән килештерергә кирәк булган очракта, тикшерү акты күчермәсе тикшерү уздыруны килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына, тикшерү актын төзегән көннән биш эш көне дәвамында җибәрелә.

3.6.10. Тикшерүче тикшерү уздыру турында язманы, юридик зат тарафыннан билгеләнгән тәртиптә алып барыла торган тикшерүләр уздыру журналына кертә.

Тикшерүләр исәбен алып бару журналы булмаган очракта, тикшерү актында тикшерүче тарафыннан билгеле язма ясала.

3.6.11. Әгәр дә планлы һәм планнан тыш тикшерү уздыру шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле заты, җитәкче яки юридик затның башка вазыйфаи заты булмау сәбәпле мөмкин булмаса, яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан эшчәнлек фактта тормышка ашырылмаса, яки тикшерү уздыруның мөмкин булмавына китергән шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле заты, җитәкче яки юридик затның башка вазыйфаи затының башка гамәлләре (гамәл кылмаулары) очрагында муниципаль контроль органы вазыйфаи заты билгеле тикшерүне уздыруның мөмкин түгеллеге турында, аны уздыруның мөмкин түгеллеге сәбәпләрен күрсәтеп, акт төзи.

Бу очракта муниципаль контроль органы билгеле тикшерүне уздыруның мөмкин түгеллеге турында акт төзегән көннән өч ай дәвамында әлеге юридик затлар, шәхси эшмәкрләргә карата планлы яки планнан тыш урынга чышып тикшерү уздыру турында, планлы тикшерүне планлы тикшерүләр уздыруның еллык планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә алдан хәбәрнамә җибәрмичә, карар кабул итәргә хокуклы.

3.6.12. Планлы тикшерү уздыру вакытында муниципаль контроль органының вазыйфаи заты тарафыннан планлы тикшерү уздырыла торган юридик затны, шәхси эшмәкәрне 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясы 1 бүлегендә күрсәтелгән затларга керткәндә һәм күрсәтелгән Законның 26.1 статьясы 2 бүлеге белән күздә тотылган нигезләр булмаган очракта, планлы тикшерү уздыру туктатыла, бу хакта билгеле акт төзелә.

3.6.13. "Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы", 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән административ җаваплылык каралган норматив хокукый актлар белән таләпләрне бозу ачыкланган очракта, тикшерү акты һәм башка тикшерү материаллары административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле органнарга яки вазыйфаи затларга тикшерү акты төзелгән көннән ун эш көне дәвамында җибәрелә.

3.6.14. Тикшерү уздырган вакытта шәхси эшмәкәр яки юридик зат тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылган очракта, тикшерүче тикшерү акты белән бергә әлеге Регламентка 2 нче кушымтадагы форма нигезендә күрсәтелгән кагыйдә бозулар турында, аларны бетерү срокларын күрсәтеп шәхси эшмәкәргз, юридик затка күрсәтмә әзерли, имза куя һәм бирә.

3.6.15. Ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында күрсәтмә шәхси эшмәкәргә яки аның вәкаләтле вәкиленә, юридик затның җитәкчесенә һәм (яки) башка вазыйфаи затка яки вәкаләтле вәкилгә расписка белән бирелә.

Ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында күрсәтмәне алудан баш тарткан очракта, шулай ук шәхси эшмәкәр яки аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның җитәкчесе һәм (яки) башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле күрсәтелгән расписканы бирүдән баш тарткан очракта, ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында күрсәтмә аны теркәгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча тикшерүче затка тапшыру турында хәбәр бирү белән заказлы почта аша җибәрелә.

3.6.16. Административ процедураны башкару һәм рәсмиләштерү сроклары.

2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьялары белән күздә тотылган һәрбер тикшерүләр уздыруның срогы әлеге Регламентның 2.2 п. күрсәтелгән.

3.6.17. Әлеге административ процедураны башкару нәтиҗәсе булып тора:

- РФ ИҮМ 141 номерлы боерыгы белән расланган формада тикшерү акты;

- планлы һәм планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру мөмкин булмавы турында акт;

- планлы тикшерүне уздыруны туктату турында акт;

- 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы 1 бүлеге 1 пункты белән күздә тотылган ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турында күрсәтмә, аларны бетерү срокларын күрсәтеп һәм (яки) чаралар уздыру;

- Ачыкланган кагыйдә бозулар турында материалларны "Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы", 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм саклау өлкәсендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле

органнарга яки вазыйфаи затларга җибәрергә (административ хокук бозуылар билгеләре булган мәҗбхри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозу фактлары ачыкланган очракта).

## 4 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬНЕ ТОМЫШКА АШЫРУНЫ КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ

4.1. Муниципалаь контроль органнары вазыйфаи затлары тарафыннан административ регламентның һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның нигезләмәләрен тоту һәм башкару, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итү буенча агымдагы контрольне тормышка ашыру тәртибе.

Вазыйфаи затларның әлеге административ регламент һәм башка норматив хокукый актларны тоту һәм башкаруны, шулай ук вәкаләтле хезмәткәрләр тарафыннан карар кабул итүне агымдагы контрольдә тоту турыдын-туры Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан тормышка аашырыла.

4.2. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм периодиклыгы, административ ренламентны башкару тулылыгы һәм сыйфаты.

Планлы тикшерүләр уздыруның тәртибе һәм периодиклыгы һәм әлеге административ процедураны башкару сыйфаты Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Шул ук вакытта тикшерүләр елга 1 мәртәбәдән дә ким уздырылмаска тиеш.

Муниципаль контрольне тормышка ашыру тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү кызыксынган затлардан шикаятьләр һәм гаризалар керү факты буенча, шулай ук билгеле контроль-күзәтчелек органнары мөрәҗәгатьләре буенча тормышка ашырыла.

4.3. Муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының алар тарафыннан муниципаль контрольне тормышка ашыру вакытында кабул ителә (тормышка ашырыла) торган карарла һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җаваплылыгы.

Тикшерү уздыру нәтиҗәләре буенча, кагыйдә бозулар ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту Россия Федерациясе законнары нигезендә тормышка ашырыла.

4.4. Муниципаль функцияне башкаруны контрольдә тоту тәртибенә һәм формаларына таләпләрне характерлаучы нигезләмәләр, шул исәптән гражданнар, аларны берләшмәләре һм оешмалары тарафыннан.

Муниципаль контрольне тормышка ашыруны контрольдә тоту юридик затлар һәм гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты адресына түбәндәгеләрне җибәрү юлы белән тормышка ашырыла:

- Биектау муниципаль районы вазыйаи затлары тарафыннан муниципаль контрольне тормышка ашыруны регламентлаучы норматив хокукый актларны камилләштерү турында тәкъдимнәр;

- законнарны һәм башка норматив хокукый актларны, әлеге регламентны, Биектау муниципаль районы, аныд хезмәткәрләре эшчәнлегендә җитешсезлекләр булуы турында хәбәрләр;

- Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары буенча шикаятьләр.

## 5 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬ ОРГАНЫНЫҢ, АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАУЛАРЫНА) СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

5.1. Кызыксынган зат муниципаль контрольне тормышка ашыру барышында кабул ителгән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаять белдерергә хокуклы.

5.2. Судка кадәр шикаять белдерү предметы булып, муниципаль контрольне тормышка ашыручы Биектау муниципаль районының вазыйфаи затларының юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең тикшерү уздырганда күздә тотылган законлы хокукларын бозуга китергән гамәлләр (гамәл кылмау), шулай ук әлеге тикшерүне тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар тора.

Кызыксынган зат шикаять белән мөрәҗәгать итәргә, шул исәптән түбәндәге очракларда да мөмкин:

1) әгәр дә тикшерү муниципаль контроль органы тарафыннан 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән күздә тотылган тикшерүләр уздыруны оештыру һәм уздыруга таләпләрне тупас итеп бозып уздырылса;

2) әгәр дә тикшерү уздыру вакытында тикшерү уздыру өчен җаваплы зат, тикшерү объекты булмаган яки тикшерү предметына кермәгән документларны тәкъдим итүне таләп итте;

3) әгәр дә тикшерү уздыру вакытында тикшерү уздыруның билгеләнгән сроклары артып китсә.

5.3. Шикаятьне карауны туктатып тору өчен нигезләр юк.

5.4. Шикаятькә җавап бирелми торган очраклар исемлеге:

1) әгәр дә мөрәҗәгатьтә кызыксынган затның исеме (юридик зат) яки фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (шәхси эшмәкәр өчен) (ахыргысы – булган очракта) һәм җавап, мөрәҗәгатькә (шикаятькә) җавап җиберелер өчен почта адресы күрсәтелмәгән булса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми;

2) әгәр дә мөрәҗәгатьтә цензурага туры килмәгән яисә хурлау сүзләре, вазыйфаи затның тормышына, сәламәтлегенә һәм милкенә, шулай ук аның гаилә әгъзаларына янау сүзләре булса, мөрәҗәгатьне карау өчен җаваплы вазыйфаи зат, анда куелган мәсьәләләрнең эчтәлеге буенча аны җаваплсыз калдырырга хокуклы, һәм мөрәҗәгатьне юллаган кызыксынган затка хокук белән исәпләшмәүнең ярамаганлыгы турында хәбәр итәргә тиеш;

3) әгәр дә мөрәҗәгать текстын укы булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми, бу хакта кыэыксынган затка хәбәр ителә, әгәр дә аның фамилиясен һәм почта адресын укып булса;

4) әгәр дә мөрәҗәгатьтә кызыксынган затка күп мәртәбә язмача аның асылы буенча җавап бирелгән мәсьәләләр булса, алда җибәрелгән мөрәҗәгатьләр белән бәйле рәвештә, мөрәҗәгатьне карау өчен җаваплы вазыйфаи зат чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсезлеге турында карар кабул итәргә һәм әлеге мәсьәлә буенча язушыларны туктатырга хокуклы. Әлеге карар турында мөрәҗәгатьне җибәргән кызыксынган затка хәбәр ителә.

5.5. Судка кадәр (судтан тыш) процедураны башлау өчен нигез булып, муниципаль контроль органына язмача формада кәгазьдә, электрон формада кергән шикаять тора.

5.5.1. Шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрен кулланып, шулай ук кызыксынган затны шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.5.2. Шикаятьтә булырга тиеш:

- карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмаулары) шикаять белдерелә торган муниципаль контроль органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең исеме;

- кызыксынган зат - шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (ахыргысы булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта алресы (адреслары) (булган очракта) һәм кызыксынган затка җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

- шикаять белдерелә торган муниципаль контроль органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты, яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

- кызыксынган зат муниципаль контроль органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты, яисә муниципаль хезмәткәрнең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмаган дәлилләр.

5.6. Кызыксынган зат гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документларны (булган очракта), яисә аларның күчермәләрен, шулай ук муниципаль контроль органында шикаятьне раслау һәм карау өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны алырга хокуклы.

5.7. Кызыксынган затлар муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) муниципаль контроль органы җитәкчесенә шикаять белдерергә мөмкин.

5.7.1. Муниципаль контроль органы җиткәчесе тарафынна кабул ителгән карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмауга) шикаятьләр Биектау муниципаль районы Башкарма комитет Җитәкчесенә бирелә.

5.8. Муниципаль контроль органына кергән шикаять, шикаять карау буенча вәкаләтләр йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан, аны теркәгәннән соң 30 көн дәвамында каралырга тиеш.

5.9. Судка кадәр шикаятьне караган вазыйфаи зат шикаятьне карау нәиижәләре буенча дәлилләнгән карар кабул итә:

- муниципаль контроль органы вазыйфаи затының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану, әгәр дә әлеге гамәлләр (гамәл кылмау) тикшерү

барышында кызыксынган затның хокукларын бозуга китергән булсалар, әлеге кагыйдә бозуларны бетерү ысулларын күрсәтеп;

- тикшерү нәтиҗәләрен бетерү турында, әгәр дә гариза бирүчегә карата тикшерү 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы 2 бүлеге белән билгеләнгән таләпләрне бозып уздырылган булса;

- шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында, баш тартуда сәбәпләрне нигезләп.


5.10. Әлеге административ регламентның 5.9 пунктында күрсәтелгән кабул ителгән карар нәтиҗәләре буенча кызыксынган затка язмача формада яки теләк буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.11. Россия Федерациясе законнарын бозуда гаеплеләргә карата чаралар турында, әлеге чаралар каблу ителгән көннән ун көн дәвамында муниципаль контроль органы язмача формада хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә хәбәр итәргә тиеш.

5.12. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаятьләр билгеләре булуы билгеләнгән очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне тормышка ашырганда, тикшерүләр үткәрүнең административ регламентына

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне тормышка ашырганда, тикшерүләр үткәрүнең административ регламентына**
**БЛОК-СХЕМА**



2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне тормышка ашырганда, тикшерүләр үткәрүнең административ регламентына

**Муниципаль контроль органының күрсәтмә**

**формасы**

(муниципаль контроль органының исеме)

**Күрсәтмә № _______**

"___" _______________ 20___ ел

_______________________________________________________________ тикшерү нәтиҗәсендә
( юридик затның, шәхси эшмәкәрнең исеме)
"______" _____________ 20___ ел № ______ акт белән, түбәндәгеләрне тормышка ашырганда гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану һәм саклау таләпләрен бозу ачыкланды:
__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________
(эшчәнлек төрен күрсәтергә)

Алда бәян ителгәннәр нигезендә түбәндәге кагыйдә бозуларны бетерү буенча чаралар күрергә күрсәтмә бирә:

| № т/б | Ачыкланган кагыйдә бозуларны кыскача тасвирлау, таләпләре бозылган норматив-хокукый актларны күрсәтеп | Кагыйдә бозуларны бетерү срогы |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |
| 3. | | |

Җитәкче ____________________ _______________________
(имза, мөһер) (инициаллар, фамилия)

_________________________